Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2:256)

# Ислам Нуры

№ 23 (651) 8 декабрь, 2017 ел (1439, Рабигүл-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Мәүлид мәҗлесе



“Туфан” мәчетендә Чаллы мөхтәсибәте Аксакаллары Шурасы (рәисе Равил хәзрәт Нуруллин, “Туфан” мәчете имам-хатыйбы) пәйгамбәребезнең (с.г.в.) туган көненә багышлап зур мәҗлес уткәрде. Анда шәһәр имамнары да катнашты. Мәҗлестә чыгыш ясап, шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормыш юлын, күркәм әхлагын халыкка аңлату өчен Мәүлид аен нәтиҗәлерәк файдаланырга чакырды, Болгарда узган Мәүлид кичәсе хакында да сөйләде.

Сөйләшү барышында аксакаллар алдагы ел өчен эш планы хакында фикер алыштылар; әхлакый тәрбиядәге кайбер проблемалар, игътибарга алынырга тиешле күп нәрсәләр, шәһәрдә эт хуҗаларын этләре артыннан җыештыруны мәҗбүри итеп куйган карар кабул итүне (Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре үрнәгендә: аларда этләрне йөрергә алып чыкканда, пакет һәм соскы алырга да онытмыйлар) сорап, шәһәр башлыгына хат юлларга килешенде. Шулай ук 17 декабрьдә шәһәр күләмендә уздырылачак Мәүлид кичәсенә әзерлек, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында хәләл туклануга күчүгә булышлык күрсәтү h.б. мәсьәләләр буенча сөйләшү булды.

## Татар халкы – мәгърифәтле халык

1 декабрьдә Чаллының “Хәләл Үзәге”ндә “Иске имля — гарәп хәрефләре, татар теле” темасына мастер класс үтте. Аны Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров һәм “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең өлкән мөгаллиме, Иске имля буенча дәреслекләр авторы Әхмәт хәзрәт Сабиров алып бардылар. Мастер класста шәһәр мәчетләренең якшәмбе мәктәбе укытучылары, имамнар, иске имля белән кызыксынучылар катнашты. Нияз хәзрәт дәрес башында халкыбызның мең ярым еллык язма мирасы, рухи байлыклары хакында сөйләде. “Татар халкының төп үзенчәлеге — аның борынгыдан китаплы, мәгърифәтле халык булуы,” — диде ул. Мастер класс барышында Әхмәт хәзрәт гарәп хәрефләренең язылышы, аның татар теленә яраклаштырылып, тагын өстәмә 10 хәреф белән тулыландырылуы, гарәпчә язу төрләре, гарәп, фарсы теленнән алынган сүзләрнең язылышы, исемнәрнең дөрес язылышы һәм башкалар хакында бай мәгълүмат бирде. Дәрес көн буена барды, фәкать җәмәгать намазларына гына тукталу булды. Чарада катнашучылар өчен “Хәләл Үзәк” тарафыннан төшке аш та әзерләнгән иде. Янәшәдәге “Сөембикә” мәчетендә Нияз хәзрәт имамлыгында җомга намазы укылды. Ул пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормыш юлы, күркәм холкы турында әчтәлекле вәгазь сөйләде.



Тарихыбызны, мирасыбызны барлаган, телебезнең исткиткеч зур байлыгын күрсәткән бу чара һәркемдә зур тәэсир калдырды. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин мастер-класс эшенә йомгак ясап, ошбу чараны оештыруга күп көч салган “Хәләл Үзәк” җитәкчесе Илдар хәзрәт Зияровка, Нияз хәзрәт һәм Әхмәт хәзрәт Сабировларга зур рәхмәтен белдерде.

Телебезне саклауга, яклауга юнәлдерелгән чаралар Чаллы мөхтәсибәтендә алга таба да дәвам итәчәк.

### Һәркем өчен бәйрәм



Болгарда бишенче тапкыр федераль масштабта Мәүлид кичәсе үтте. Чара беренче мәртәбә Болгар ислам академиясе бинасында ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылды. Тантанада баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Иран Ислам Республикасының Казандагы генераль консулы вазыйфаларын башкаручы Алибеман Эгбали Зарч, Төркия Республикасының мәшһүр Коръән-хафизы Исхак Даныш, Россия һәм Татарстаннан дин әһелләре, остазлар, шәкертләр, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

* * *



Чаллы шәһәренең “Рамазан” мәчетендә Мәүлид көненә багышланган кичә узды. Мәчет имам-хатыйбы Фәрхәд хәзрәт Гайфуллин Пәйгамбәребез с.г.в.нең матур әхлагы турында сөйләде, Коръән аятьләре укыды. Вәгазьдән соң мөнәҗәтләр дә башкарылды, аш мәҗлесе дә уздырылды.

* * *

Чаллының “Әбу-зәр” мәчетендә гадәттәгечә күркәм чаралар уздырылды. “Мәүлид кичәсе уңаеннан мәхәлләнең мохтаҗлар һәм физик мөмкинлекләре чикле кешеләренә күчтәнәч таратылды. Мондый бүләккә 45 кеше кабул итеп алды”, — ди мәчетнең имам-хатыйбы Али хәзрәт Бәһаветдин.



# Барысы да бер Аллаһтан!

**Кадерле дин кардәшләрем!**

**Муса галәйһи сәлам һәм Фиргавеннең иң куәтле сихерчеләренең көч сынашулары турында укыганыгыз, ишеткәнегез бардыр. Фиргавеннең Аллаһы Тәгаләнең могҗизаларыннан өстенрәк булырга тырышуы хакында да укыгансыздыр.**

Әмма ул аны булдыра алмады. Дөньяның төрле почмакларыннан чакырып алынган иң яхшы сихерчеләр Муса галәйһи сәламнең могҗизаларын күреп, моның бер Аллаһтан икәнен аңладылар, бер Аллаһка ышандылар һәм мөселман булдылар. Хәтта Фиргавеннең җәзасы да куркытмады аларны. Алар газаплы үлемне сайладылар. Үзләренең тормышларын диннәрен саклап калу өчен корбан иттеләр.

Муса белән сихерчеләр арасындагы көч алышу һәм Муса галәйһи сәламнең җиңеп чыгуы барча халыкны тетрәндерде. Беренче тапкыр кемдер Фиргавенгә каршы чыга. Алай гына да түгел, Муса галәйһи сәламнең көндәшләре җиңелеп кенә дә калмый, хәтта үзләре дә Муса галәйһи сәламнең динен, ислам динен кабул итәләр. Барча халык моны күреп, тетрәнә. Фиргавен һәм аның якыннары халык өстеннән хакимлек итүне югалтудан курка башлыйлар. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында әйтә: "Фиргавен кавеменең олылары әйттеләр: "Ий, Фиргавен! Муса һәм аның кавеменә җир өстендә бозыклык таратуны һәм сиңа һәм синең илаһләреңә гыйбадәт кылудан баш тартырга рөхсәт итәсеңме син?" Фиргавен әйтте: "Без аларның кыз балаларын калдырып, ир балаларын үтерербез. Без, әлбәттә, алардан өстенбез, көчлебез." [1]

Карагыз әле, начар кешеләр арасында булуың сиңа ничек начар тәэсир итә!!!

Ибн Касир әйтә: "Нәкъ шушы начар кешеләр арасында булу Фиргавенгә начар тәэсир итә. Алар Фиргавенне Муса галәйһи сәламгә һәм аның кавеменә зыян китерергә өндиләр. Фиргавенне Муса галәйһи сәлам алып килгән хак дингә чакырасы урынга, бер Аллаһка гыйбадәт кылуны алар бозыклык тарату дип атыйлар.

Сөбеханаллаһ! Аллаһка гыйбадәт кылу бозыклыкмы әллә?! Алайса, Фиргавенгә һәм төрле сыннарга гыйбадәт кылу яхшы гамәл дип аталамы?!

Исраил халкының хәлен күз алдына китерегез. Әллә алар үзләренең якыннары өчен кайгырмаганнармы? Аларның якыннары куркыныч астында. Әмма Муса төшенкелеккә бирелми. Бар нәрсә бер Аллаһ кулында икәнен бик яхшы аңлый. Ул үз халкына йөрәкләрен Аллаһ белән бәйләргә куша. Йөрәкләрне бер Аллаһ белән бәйләү — уңышка китерүче гарантия. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Муса галәйһи сәлам үз кавеменә әйтте: "Аллаһтан ярдәм сорагыз һәм сабыр итегез! Бит җир Аллаһы Тәгаләнеке. Ул җиргә Үзе теләгән бәндәсен хуҗа кылыр, әшнең ахырындагы шатлык вә уңыш тәкъва мөэминнәргә». [2]

[1] Сура аль-Аграф 127
[2] Сура Аль-Аграф 128

Һәм дәвам итеп, үз халкына болай ди: "Бәлки, Раббыгыз сезнең дошманнарыгызны тиздән һәлак итәр һәм алар урынына сезне хәлиф ясар, аннан ничек эш кылганыгызны карар!" [3]

Җәмәгать, бүгенге көндә дә моңа мисаллар җитәрлек. Әйтик, татар теленең торышы, бетеп, юкка чыгарга мөмкин икәнен барчабыз да ишетеп беләбез. Кешеләрнең бу хәлгә борчылганнарын еш ишетергә туры килә. Әйе, бу зур проблема. Әмма... Аллаһы Тәгаләдән телебезне саклап калуны сорап дога кылдыкмы соң? Аллаһы Тәгаләдән балаларыбызны миллионнарча мөселманнар сөйләшүче телебездә тәрбия кылуны сорадыкмы без? Кадерле дин кардәшләрем! Төрки халыклар, Урта Азия халкына хас туган телебезне, төрки телебезне югалту куркынычы яный безгә. Кая безнең догаларыбыз?! Ихлас догаларыбызны кабул итеп, Аллаһы Тәгалә бу хәлгә яхшы, уңай чишелеш бирергә мөмкин бит. Һәм бер генә кеше дә Аллаһы Тәгаләнең әмеренә каршы килә алмас.

Муса галәйһи сәлам Аллаһы Тәгаләгә бу сүзләр белән мөрәҗәгать итә: "Кыямәт көненә ышанмаган һәм тәкәбберләнүче явызлыгыннан минем һәм сезнең Раббыгыз булган Аллаһка сыгынамын." [4]

Карагыз, Муса галәйһи сәлам Аллаһтан сорый, аның халкы бер Аллаһы Тәгаләдән сорый! Алар Аллаһка сыеналар, Аллаһтан аларны саклауны сорыйлар.

Нәтиҗә озак көттерми. Аллаһы Тәгалә Фиргавеннең бертуганының улын иманга китерә. Ул Муса галәйһи сәламне һәм аның кавемен яклап чыга. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримендә әйтә: "Фиргавен хезмәтендә булган, иманын яшерүче бер мөэмин ир әйтте: "Ий, кавемем, бер ир минем Раббым — Аллаһ дигәне өчен генә аны үтерәсезме? Ул сезгә Раббыгыздан ачык дәлилләр белән килде. Әгәр ул ялган сөйләсә, зарары үзенә булыр. Әгәр сөйләгән сүзләре хак булса, сезгә вәгъдә иткән газабы ирешер. Хаклыкта, Аллаһ хакны инкяр итүче, чиктән үткән фасыйкны, ялган сөйләүчене туры юлга күндермәс." [5]

Ибн Касир әйтә: "Бу кеше иманын качырып килгән. Әмма Фиргавен Муса галәйһи сәламне һәм Муса галәйһи сәламнең кавемен җәзалап газаплаячагын белгәч, алар өчен куркып, Муса галәйһи сәламне яклап чыккан", - ди. Карагыз әле, ничек акыллы һәм йомшак була бу кешенең сүзләре! Ул әйтә: "Минем Раббым — Аллаһ" дигәне өчен генә аны үтерәсезме? Бары тик шушы сүзләрне әйткәне өчен генә ул үлемгә лаекмы? ди ул. Киресенчә, бу кеше хөрмәткә лаек.

Аннан болай ди: "Ул сезгә Раббыгыздан ачык дәлилләр белән килде." Ягъни аның сүзләре буш түгел, ул сүзләренең хак булуына ачыктан-ачык дәлилләр китерә.

Аннан бу кешеләрне тынычландырыр өчен: "Әгәр ул ялган сөйләсә, зарары үзенә булыр," - ди. Ягъни алдашса, ялганның зыяны бары тик аңа гына зыян итә, ди ул.

[3] Сура Аграф 127-129
[4] Сура Гафир 27
[5] Сура Гафир 128

"Әгәр сөйләгән сүзләре хак булса, сезгә вәгъдә иткән газабы ирешер". Ягъни, сез аңа тимәсәгез, һәм аның сүзләре хак булса, сезгә каты газапның күпмедер өлеше генә ирешер", - ди.

Шуннан Фиргавеннең бертуганының улы Фиргавенне һәм аның якыннарын куркытыр өчен әйтә: "Ий, кавемем. Бүген хакимлек сезнең кулда, һәм сез җирдә хакимлек итәсез. Әмма Аллаһның газабы килсә, ул газаптан сезне кем коткарыр?"

Җәмәгать, бу сүзләр тирән акыл белән әйтелгән сүзләр.

Ибн Касир әйтә: "Ягъни, бу Фиргавен һәм аның якыннарының хакимлекләрен югалтуга сәбәп булырга мөмкин. Чөнки Аллаһы Тәгаләнең җир шарында тәртибе шундый: дәүләт дингә һәм дин әһелләренә зыян китерсә, Аллаһы Тәгалә аларның хакимлеген ала. Һәм алар югары дәрәҗәләрен югалтып, түбәнгә төшереләләр. Нәтиҗәдә Фиргавен белән дә шулай була. Бүгенге көндә дә Аллаһның бу тәртибе дәвам итә. Аллаһның диненә һәм Аңа якын кешеләргә зарар китерергә теләгән саен, Аллаһы Тәгалә бу золымлык кылучыларның хакимлеген ала.

Шуннан бу ир кеше кавеменә Кыямәт көнен һәм Аллаһның алардан алда килгән кавемнәрне юкка чыгаруын исләренә төшерә: «Ий, кавемем, үткән өммәтләргә ирешкән газапның сезгә дә ирешүеннән куркамын. Нух, Гад, Сәмуд вә алардан соң килгән пәйгамбәрләрне җәберләүче залим кавемнәргә килгән һәлакәт сезгә дә килер дип куркам. Аллаһы Тәгалә колларына гаделсезлек кылмый. Ий, кавемем! Сезгә Кыямәт көне килүеннән куркамын. Ул көнне берәүләр икенчеләреннән ярдәм сорап кычкырырлар. Ул көнне артка әйләнеп качарга теләрсез, ләкин Аллаһтан сезне беркем сакламас."

Муса галәйһи сәлам Фиргавен һәм аның якыннарының бу сүзләргә игътибар итмәгәнен күреп: "Ий, кавемем! Мин сезне уттан котылырга чакырамын, ә сез мине ут газабына чакырасыз. Мин әйткән сүзләрне тиздән исегезгә төшерерсез. Мин үземнең эшемне Аллаһка тапшырдым. Хаклыкта, Аллаһ колларын күрә", - ди.

Бу кешенең сүзләре Фиргавен һәм аның якыннарының фикерен үзгәртмәсә дә, Муса галәйһи сәламне һәм аның кавемен каты җәзага тотылудан, бәлки, коткаргандыр.

Җәмәгать, Муса галәйһи сәламнең тарихыннан бу турыда, бәлки, укыганыгыз да булгандыр. Әмма бу вакыйгага артык игътибар бирелмәгәндер. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһи сәламне һәм аның кавемен нәкъ менә шушы кешенең яклап чыгуы аша һәм Муса галәйһи сәламнең һәм аның халкының эчкерсез күңелдән кылынган догалары сәбәпле коткарадыр.

**Әбүбәкер хәзрәт Әдбиев,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

## СОРАУ-ҖАВАП

Укучыларны кызыксындырган сорауларга шәригать белгече **Рәфыйк Миннәхмәтов** җавап бирә:

**– Әссәләмугаләйкум! Быел бик кайгылы елыбыз булды: 5 яшьлек оныгыбыз авырып үлеп китте. Аның өчен доганы ни рәвешле кылырга икән? Ул сабыйның бер гөнаһы да юк бит, дога кылганда нәрсә дип сорарга кирәк?**

**Асия, Тукай районы.**

– Бу очракта "Кыямәт көнендә ата-анасына, туганнарына ул гөнаһсыз баланың шәфәгате булса иде", - дип Аллаһы Тәгаләдән сорап дога кылу иң хәерлесе булыр.

**– Әссәламугаләйкум! Без "Ислам нуры" газетасын инде күп еллар яздырабыз, бик яратып укыйбыз. Бу сорауны сезгә телефон аша гына бирәм, гаеп итмәссез. Соравым гади генә тоелса да, аңа берәр шәригать белгече җавап бирсә иде. Хатын-кызлар үзара кул биреп күрешкәндә, кышкы салкыннарда бияләйне салу мәҗбүриме? Без инде олы яшьтәгеләр, бияләйне салсаң, кул бик тиз туңа. Салмыйча гына исәнләшүебез гөнаһ түгелме, дин күзлегеннән ничегрәк икән? Шушы хакта сүз алыштык та, сезгә шалтыратырга булдык.**

**Рауза ханым, Киров өлкәсе.**

– Бияләйсез күрешү, әлбәттә, әдәп ягыннан күркәмрәк, яхшырак. Шулай да бик салкын булса, бияләйне салмыйча күрешкәндә дә сөннәт үтәлә, болай эшләү тыелмый.

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән*

# Йөрәк бабай һәм падишаһ

*(Хикәят. Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе. Дәвамы)*

ҖАҺИТ ЗАРИФОГЛУ

Болар чатыр янында утырганда, анда Йөрәк бабай белән Айшә әби дөяне чалу турында ишетелерлек итеп сөйләшкәннәрен, аһ-ваһ килүләрен ОНЫТАЛАР. Әлбәттә, моңа бераз картлык та сәбәптер...

Падишаһ та, вәзирләре дә аларның сөйләшкәннәрен ишеткәннәр. Әммә падишаһ вәзирләрен ахырга кадәр туктатып торган. "Туктагыз, нишлисез сез?! Кыен хәлгә төшәрсез, мескенләнеп бетәрсез, дөякәйне чала күрмәгез!" — дип әйтмәгән.

Ул әйтмәгәч, дөякәйне суйганнар. Вәзирләр дә сабырлык белән күзәткәннәр.

Йөрәк бабай белән Айшә әби сәгатьләр буе мәш килгән. Итне чистартып, иң яхшы кисәкләрен, кайсын пешерергә, кайсын кыздырырга дип аерып куйганнар. Һәм шулай итеп, падишаһларны күздә тотып, бер табын әзерләгәннәр. Өстенә кара борыч сибелгән ит шулпасында булгур пылавы парланып пешкән; әйрән, катык, тегесен-монысын дигәндәй, тауның, болыннарның иң шифалы үләннәрен, һәр авыруга шифа булсын дип, итләр, катыклар янына куйганнар.

Падишаһ һәм янындагылар туйганчы рәхәтләнеп ашаганнар. Аннан падишаһ дога укырга тотынган. Үзенең падишаһ икәнен барыбер белгертмәгән. Китәр алдыннан картка әйткән:

— Әнә, каршыда бер шәһәр, булганың бармы анда?

— Юк, һич язмыш ташламады ул якларга.

— Анда пайтәхет бит, беләсеңме? Бер илнең, императорлыкның баш шәһәре пайтәхет дип йөртелә. Ягъни тәхете булган шәһәр. Анда падишаһ утыра. Нинди дип беләсең аны?

— Аны бик бөек, бик гадел, мәрхәмәтле дип беләм. Күңеле киң, беләге көчле булсын. Һәр намазымда аның һәм дөньясы, һәм дә ахирәте өчен дога кылам. Аллаһ аны сакласын, аның өчен мин бик борчылам.

— Нигә борчыласың, Йөрәк бабай?

— Борчылмыйча. Без йон чатыр белән, беткән казанның хисабын теге дөньяда ничек бирербез дип куркып торабыз. Әгәр аңа мал-мөлкәте турында сорау бирелсә, нәрсә дип әйтер, нәрсә сөйләр? Җиңел генә җавапларын бирсен иде, Раббым! Менә бусы да аның сираты. Сират күпере.

Падишаһ дерелдәп куя.

— Ярар, байтак вакыт үтте. Әле барасы юллар шактый, караңгыга калсак, юлбасарларның очравы бар.

— Мин үземне белгәннән бирле юлбасарлар бу тирәләрдә булмады. Падишаһыбыздан Аллаһ риза булсын. Аның дәүләтендә юлбасарлар барлыкка килсә, димәк, кыямәт кубачак.

— Шулай дисеңме?

— Әйе, шулай дим. Әгәр бер илдә һәркем мул яшәгәннән соң һаман караклар була икән, әгәр бер илдә тулы гаделлек булып та юлбасар барлыкка килсә, кыямәт галәмәтләредер, улым. Аллаһ падишаһыбыздан риза булсын. Ярар, балаларым, әйдәгез, соңга калмагыз. Дога кылыгыз.

— Ә, - диде падишаһ, нәрсәнедер исенә төшереп. — Ул шәһәрдә олы мәчет бар. Үзәк мәчет дип атала. Падишаһ һәр җомгада ул мәчеткә килеп, намаз укып, вәгазь сөйли, нәсихәт бирә. Халыкны тыңлый. Мохтаҗ булганнарга кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтә. Син дә бу җомгада шунда бар, син дә берәр нәрсә сора. Ул сине кабул итәр, сараена алып китәр, сый-хөрмәт күрсәтер.

— Күпме мохтаҗлар була торып, падишаһны борчуыбыз дөрес булырмы?

Падишаһ тез чүгеп, Йөрәк бабайның кулын үбеп, үзен фаш итәр кебек иде. Ләкин үзен тотып калды.

— Бабакай, үтенеп сорыйм: бер мәртәбә булса да барып кил һәм күреп кал, ерактан сөеп хөрмәтләгән падишаһың моңа лаекмы икән? Син дә үз бәяңне әйт.

— Ярар, балам, барырмын. Бәлки яхшы да булыр, безнең дә ихтыяҗыбыз табылыр, кем белгән. — Йөрәк бабай шулай дигән һәм эчтән генә: "Минем җан юлдашыма бер дөя алырга бер бакыр акча бирер, бәлкем. Бик яхшы булыр иде", — дип уйлап куйган.

Мосафирлар атларына атланганнар. Дөм караңгы булганчы шәһәргә кайтып җитәргә дип атларын куганнар.

Йөрәк бабай чатырга кайтты.

— Ханым, син эшнең ахырын ишетми калдың. Башлыклары булган матур буй-сынлы зат миңа шулай-шулай диде. Нәрсә әйтәсең, берничә көн бу тирәләрдә калып, җомгага анда төшимме икән?

— Иркәем, сиңа бу олы затлар бу акылны биргән икән, әлбәттә, алар миннән яхшырак беләләрдер.

— Синнән генәме, миннән дә яхшырак белә алар.

— Миннән яхшы беләләр белүен, әмма синнән яхшы белүләренә килгәндә, син алардан яхшырак беләсең.

— Хатынкай, миңа кайдан бу кадәр ышаныч?

— Хатын өчен иреннән дә яхшырак уйлаучы ир-ат булмый. Иң яхшысын ире генә уйлый ала.

— Их син, нинди ягымлы кеше!

Бу юлы да бергәләшеп башларын мендәргә куйдылар. Һәм балдан татлы итеп йокыга талдылар.

Җомга көн. Елгалар, таулар аша Йөрәк бабай шәһәргә килеп җиткән. Олы мәчетне дә тапкан. Карый, анда халык шактый күп. Караса, кешеләрнең барысы бер якка агылалар, кайнашалар. Башын борып караса, бераз алдарак падишаһ хәзрәтләре. Кайсы аның белән сөйләшергә тели, кайсы үтенеч җиткерә.

Йөрәк бабай урынында шул рәвешле котеп калган. Моның кадәр халыктан соң чират җитмәс, дигән. Һәм падишаһны карап калырга, йөзен-күзен хәтеренә сеңдерергә теләгән. Кайткач Айшә әбигә сөйләп күрсәтәсе бар бит әле! Тагын үзенчә уйлана: "Мохтаҗ кешеләр никадәр күп икән. Боларның барысы да, һәрхәлдә, бөтенләй фәкыйрьләр, хәсрәтле кешеләрдер. Аллага шөкер, бар нәрсәбез дә бар, Ходай безгә һәрнәрсәне мул итеп биргән. Юкса, билгеле, мин дә монда килеп, бу капкада ярдәм теләнер идем".

Шулай дигән дә, падишаһның күзләре бик ерактан аңа карамасынмы?! Шулкадәр оялган, тиз генә башын түбән игән. Ул башын шулай иеп торганда, тавышлардан, этеш-төртешләрдән ниндидер хәл булганын аңлап алды. Тавышлар бераз басылгач, өченнән генә: "Нәрсә булды икән?" - дип әйтергә өлгермәгән, башын күтәрүгә, караса, падишаһ каршысында басып тора түгелме?

*(Дәвамы бар)*

*Безгә язалар*

# Кайда синең горурлыгың, әй, татарым?!

Хәзерге вакытта "тел бетә, дин бетә" дип зарланабыз, кемнәрне генә сүкмибез, пикетлар ясыйбыз, кемгә генә мөрәҗәгать итмибез. Бу, минемчә, суга батучының саламга тотынып калырга теләвенә тиң. "В контакте" социаль челтәрендә "Татарлар Собчак өчен" төркемә оештырылды. Төркемдә катнашучылар Русия Президентлык вазыйфасына дәгъва кылган Ксения Собчактан туган тел язмышын хәл итүдә ярдәм сорый. Шәхсән үземә бу ачык хат башка милләттән үз-үзеңне мыскыл иттерүгә тиң кебек тоелды. Ий, халкым, кайда синең горурлыгың?

Бу мәкаләне язарга мине Зөфәр хәзрәт Галиуллинның "Безнең гәҗит"тәге (18 октябрь 2017 ел) "Сарык булмагыз, ник үз телегездә сөйләшергә рөхсәт сорыйсыз?" дигән тетрәндергеч язмасы этәрде. Минем бу мәсьәләдәге фикерләрем тулысынча аның фикерләре белән тәңгәл килә. Үз чиратында мин Зөфәр әфәндедең, "Ислам нуры" газетасында үзе язган хезмәтеннән өзекләрне танып, мине урлауда гаепләп җавапчылыкка тартмавына ышанып калам һәм аңардан гафу үтенәм. Бу бүгенге көннең актуаль темасы булганга күрә, безнең шәһәрнең бердәнбер дини газетасында урын алырга тиеш дип уйладым.

Халыкны халык иткән телләре, үзаңнары, гореф-гадәтләре, диннәре дә Аллаһы Тәгаләдән. Һәр халык хөрмәткә лаек. Моны тел, дин, халык белән тартышучы бәндәләр аңласалар иде. Тыныч, дустанә яшәү урынына дошманлык, низаг, тарткалашу-бүленү кемгә кирәк? Нәрсә бүләбез, кемгә ни җитми?

Әй, кеше! Аллаһы Тәгалә сиңа иң олы дәрәҗә бирде, сине хәлифә итте, хайван, бөҗәк, сарык түгел, ә хәлифә! Сарык булмагыз, ни өчен Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткәнне — сезне халыклар итеп яралтканын исегездән чыгарып, Аллаһының нигъмәтен онытып, хөкүмәттән үз телегездә сөйләшергә рөхсәт сорап йөрисез? Аллаһы Тәгалә нигъмәтеннән нигъмәтләнегез. Без, татарлар, Русиянең җимерелүен теләмибез, без тезеген дәүләт ул. Без дә халык, без дә хокуклы, безнең дә бабаларыбыз, аталарыбыз яуларда шушы ил өчен кан түккән — ирек өчен, Ватан өчен, дәүләт өчен. Дәүләт ул — мирас, безнең телебез, үзаңыбыз, динебез, гореф-гадәтләребез, тарихыбыз, икътисадыбыз. Инде бүген бабаларыбызның мирасларын аяк астына салып таптыйкмы? Әгәр без бүген үзебезнең куркаклыкны саклык дип атасак, балаларыбыз үзләренең коллыкларын ватанпәрвәрлек дип атарлар. Балаңның кол булуын телисеңме? Теләмәсәң, мәхрүм итмә нарасыеңны ана теленнән, бөек тарихыңнан, Кол Галиеңнән, Утыз Имәниләрдән, Тукай, Туфан, Җәлилләрдән. "Олы юлның тузаны"н татысын ул, "Кандыр буе"на барып битен юсын, Идел суын колачлап йөзсен, азан тавышыннан күңеле үссен. Мин татар дип горурланып әйтсен. Әй, татар кешесе! Син дәүләтләр тоткан халык, дөньяга галимнәр, язучылар, көрәшчеләр биргән китаплы халык. Аллаһы Тәгалә сине дан-шөһрәт белән сынады, яу кырларында сынаldың. Инде Аллаһы Тәгаләдән булган бүгенге вәзгыятьтә сынма-сынатма. Аллаһы Тәгалә Коръән-Кәримдә әйтә: "Сабыр бул, Аллаһы Тәгаләнең әмере килер, үзеңне — асылыңны югалтма,"- ди. Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе, әлбәттә, үтәлер.

Татар халкына каршы нинди генә ысуллар кулланып көрәшсәләр дә, без үзебезне хәрам балтасы астына куймаска тиеш. Чеп-чи татар авылларында татар мәктәпләрен урыска әйләндерүне тыярга, Бердәм дәүләт имтиханын татар телендә бирдерүне таләп итәргә, балалар бакчасыннан алып Фәннәр Академиясенә кадәр белем йортлары, Фәнни үзәкләре булдырырга тиеш. Әлхәмдүлилләһ, яңа ачылган Болгар Ислам академиясе тарихи бәйләнешне яңадан тергезер, гыйльми җепләр өзелмәс.

Депутатлар сайладык, беренчеләрдән булып бу эшкә укытучылар тырышлык куйды. Татар авыллары сайлауда 99 % катнашты. Бүген кайда ул сайланган депутатлар? Сайлау алдыннан телләре ачылган иде, сайланганнан соң тыннары да чыкмый. Сайлауларда тырышлык куйган татар теле укытучыларына бүген эшсезлек яный.

Мөхтәрәм җәмәгать! Дөрес нәтиҗә ясыйк, алга таба бу фаҗигале юлдан баруыбызны туктатыйк. Туган телебездә фикерлик. Татарча сөйләшик, үзебезчә сөйләшә торган иманлы балалар үстереп калдырыйк. Шулай булганда гына милләтебезнең киләчәге өметле булыр.

Тел һәм дин мәсьәләсенә килгәндә, алар гасырлар буе бер-берсен саклап килгәннәр. Әгәр кеше теленнән язса, бик тиз иманнан дингә кичүе ихтимал. Шулай ук диненнән язса, телен югалтуы да мөмкин. Мәчетләрдә вәгазьләрне бары тик татар телендә генә алып баруыбыз моңа юл куймас дип ышанасы килә. Кеше дингә барыбер кайтачак. Динсез кешенең күңеле беркайчан да тыныч була алмый, динсез булып китәсе килми. Телне саклау җәмгыятьнең әйдәп баручы кешеләреннән тора. Һәрбер милләттә ул иң күп дигәндә 10%, калганнары — ияручеләр. Һәрбер буында алдынгы яшьләр көче кирәк безгә. Көрәшеп булмый дигәнгә ышанасы килми. Бөтендөнья татар конгрессы, "Милли шура", Татар Иҗтимагый Үзәге вәкилләре Конституция белән беррәттән Аллаһ кушкан кануннардан тайпылмыйча эш итсәләр иде. Бу очракта изге ниятләребездә Аллаһ ярдәмче булыр иде, иншә Аллаһ.

**Минсабир Вәлиев,**
**Чаллының "Ихлас" мәчете**
**Аксакаллар шурасы рәисе.**

# Намаз вакытлары

| Милади Гыйнвар | Көн исеме | Раб. ахир, Җөм.-әүвәл | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Иртәнге намаз: Таң беленә Чаллы | Иртәнге намаз: Таң беленә Казан | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла Уфа | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла Чаллы | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дш | 14 | 07.23 | 05.40 | 05.53 | 08.09 | 06.29 | 06.43 | 09.39 | 07.59 | 08.13 | 13.19 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.12 | 13.20 | 13.33 | 16.59 | 15.07 | 15.20 | 18.53 | 17.05 | 17.18 |
| 2 | Сш | 15 | 07.23 | 05.39 | 05.53 | 08.09 | 06.29 | 06.42 | 09.39 | 07.59 | 08.12 | 13.19 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.13 | 13.21 | 13.34 | 17.00 | 15.09 | 15.22 | 18.54 | 17.06 | 17.19 |
| 3 | Чш | 16 | 07.23 | 05.39 | 05.53 | 08.08 | 06.29 | 06.42 | 09.38 | 07.59 | 08.12 | 13.20 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.14 | 13.23 | 13.35 | 17.01 | 15.10 | 15.23 | 18.55 | 17.07 | 17.20 |
| 4 | Пҗ | 17 | 07.23 | 05.39 | 05.52 | 08.08 | 06.28 | 06.42 | 09.38 | 07.58 | 08.12 | 13.20 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.15 | 13.24 | 13.37 | 17.02 | 15.11 | 15.24 | 18.56 | 17.08 | 17.21 |
| 5 | Җм | 18 | 07.23 | 05.39 | 05.52 | 08.08 | 06.28 | 06.42 | 09.38 | 07.58 | 08.11 | 13.20 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.16 | 13.25 | 13.38 | 17.04 | 15.13 | 15.25 | 18.57 | 17.09 | 17.22 |
| 6 | Шм | 19 | 07.23 | 05.39 | 05.52 | 08.07 | 06.27 | 06.41 | 09.37 | 07.57 | 08.11 | 13.21 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.17 | 13.26 | 13.39 | 17.05 | 15.14 | 15.27 | 18.58 | 17.10 | 17.23 |
| 7 | Як | 20 | 07.22 | 05.39 | 05.52 | 08.07 | 06.27 | 06.40 | 09.37 | 07.57 | 08.10 | 13.21 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.19 | 13.28 | 13.41 | 17.06 | 15.16 | 15.28 | 18.59 | 17.12 | 17.25 |
| 8 | Дш | 21 | 07.22 | 05.38 | 05.52 | 08.06 | 06.26 | 06.39 | 09.36 | 07.56 | 08.09 | 13.22 | 11.36 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.20 | 13.29 | 13.42 | 17.08 | 15.17 | 15.30 | 19.00 | 17.13 | 17.26 |
| 9 | Сш | 22 | 07.21 | 05.38 | 05.51 | 08.05 | 06.25 | 06.39 | 09.36 | 07.55 | 08.08 | 13.22 | 11.37 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.22 | 13.31 | 13.43 | 17.09 | 15.19 | 15.31 | 19.01 | 17.14 | 17.27 |
| 10 | Чш | 23 | 07.21 | 05.38 | 05.51 | 08.04 | 06.25 | 06.38 | 09.35 | 07.55 | 08.07 | 13.23 | 11.37 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.23 | 13.32 | 13.45 | 17.11 | 15.20 | 15.33 | 19.03 | 17.15 | 17.28 |
| 11 | Пҗ | 24 | 07.21 | 05.37 | 05.51 | 08.03 | 06.24 | 06.37 | 09.34 | 07.54 | 08.06 | 13.23 | 11.38 | 11.51 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.24 | 13.34 | 13.46 | 17.12 | 15.22 | 15.35 | 19.04 | 17.17 | 17.30 |
| 12 | Җм | 25 | 07.20 | 05.37 | 05.50 | 08.02 | 06.23 | 06.36 | 09.33 | 07.53 | 08.05 | 13.24 | 11.38 | 11.51 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.26 | 13.35 | 13.48 | 17.14 | 15.24 | 15.36 | 19.05 | 17.18 | 17.31 |
| 13 | Шм | 26 | 07.20 | 05.36 | 05.50 | 08.01 | 06.22 | 06.35 | 09.32 | 07.52 | 08.04 | 13.24 | 11.38 | 11.52 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.27 | 13.37 | 13.50 | 17.16 | 15.25 | 15.38 | 19.07 | 17.19 | 17.32 |
| 14 | Як | 27 | 07.19 | 05.35 | 05.49 | 08.00 | 06.21 | 06.34 | 09.31 | 07.51 | 08.03 | 13.24 | 11.39 | 11.52 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.29 | 13.38 | 13.51 | 17.19 | 15.27 | 15.40 | 19.08 | 17.21 | 17.34 |
| 15 | Дш | 28 | 07.19 | 05.35 | 05.48 | 07.59 | 06.20 | 06.33 | 09.30 | 07.50 | 08.02 | 13.25 | 11.39 | 11.52 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.31 | 13.40 | 13.53 | 17.21 | 15.29 | 15.42 | 19.09 | 17.22 | 17.35 |
| 16 | Сш | 29 | 07.18 | 05.34 | 05.48 | 07.58 | 06.19 | 06.32 | 09.29 | 07.49 | 08.01 | 13.25 | 11.39 | 11.53 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.32 | 13.42 | 13.55 | 17.23 | 15.31 | 15.44 | 19.11 | 17.24 | 17.37 |
| 17 | Чш | 30 | 07.17 | 05.33 | 05.47 | 07.57 | 06.18 | 06.31 | 09.28 | 07.48 | 08.00 | 13.25 | 11.40 | 11.53 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.34 | 13.43 | 13.56 | 17.25 | 15.33 | 15.45 | 19.12 | 17.25 | 17.38 |
| 18 | Пҗ | 1 | 07.16 | 05.32 | 05.46 | 07.56 | 06.16 | 06.30 | 09.27 | 07.46 | 07.59 | 13.26 | 11.40 | 11.54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.36 | 13.45 | 13.58 | 17.26 | 15.34 | 15.47 | 19.14 | 17.27 | 17.40 |
| 19 | Җм | 2 | 07.15 | 05.31 | 05.45 | 07.54 | 06.15 | 06.28 | 09.26 | 07.45 | 07.58 | 13.26 | 11.40 | 11.54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.37 | 13.47 | 14.00 | 17.27 | 15.36 | 15.49 | 19.15 | 17.28 | 17.41 |
| 20 | Шм | 3 | 07.14 | 05.31 | 05.45 | 07.53 | 06.14 | 06.27 | 09.24 | 07.44 | 07.57 | 13.26 | 11.41 | 11.54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.39 | 13.49 | 14.02 | 17.28 | 15.38 | 15.51 | 19.17 | 17.30 | 17.43 |
| 21 | Як | 4 | 07.13 | 05.30 | 05.44 | 07.52 | 06.12 | 06.26 | 09.23 | 07.42 | 07.56 | 13.26 | 11.41 | 11.54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.41 | 13.50 | 14.03 | 17.30 | 15.40 | 15.53 | 19.18 | 17.31 | 17.45 |
| 22 | Дш | 5 | 07.12 | 05.29 | 05.43 | 07.50 | 06.11 | 06.24 | 09.22 | 07.41 | 07.54 | 13.27 | 11.41 | 11.55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.43 | 13.52 | 14.05 | 17.32 | 15.42 | 15.55 | 19.20 | 17.33 | 17.46 |
| 23 | Сш | 6 | 07.11 | 05.27 | 05.42 | 07.49 | 06.10 | 06.23 | 09.20 | 07.40 | 07.53 | 13.27 | 11.42 | 11.55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.45 | 13.54 | 14.07 | 17.34 | 15.44 | 15.57 | 19.22 | 17.35 | 17.48 |
| 24 | Чш | 7 | 07.10 | 05.26 | 05.41 | 07.48 | 06.08 | 06.21 | 09.19 | 07.38 | 07.51 | 13.27 | 11.42 | 11.55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.46 | 13.56 | 14.09 | 17.36 | 15.46 | 15.59 | 19.23 | 17.36 | 17.49 |
| 25 | Пҗ | 8 | 07.09 | 05.25 | 05.40 | 07.46 | 06.06 | 06.20 | 09.18 | 07.36 | 07.50 | 13.28 | 11.42 | 11.55 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.48 | 13.58 | 14.11 | 17.38 | 15.48 | 16.01 | 19.25 | 17.38 | 17.51 |
| 26 | Җм | 9 | 07.07 | 05.24 | 05.38 | 07.44 | 06.05 | 06.18 | 09.16 | 07.35 | 07.48 | 13.28 | 11.42 | 11.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.50 | 14.00 | 14.13 | 17.40 | 15.50 | 16.03 | 19.26 | 17.40 | 17.53 |
| 27 | Шм | 10 | 07.06 | 05.23 | 05.37 | 07.43 | 06.03 | 06.16 | 09.14 | 07.33 | 07.46 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.52 | 14.02 | 14.15 | 17.42 | 15.53 | 16.05 | 19.28 | 17.41 | 17.55 |
| 28 | Як | 11 | 07.05 | 05.22 | 05.36 | 07.41 | 06.02 | 06.15 | 09.13 | 07.32 | 07.45 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.54 | 14.04 | 14.17 | 17.44 | 15.55 | 16.08 | 19.30 | 17.43 | 17.56 |
| 29 | Дш | 12 | 07.04 | 05.20 | 05.35 | 07.39 | 06.00 | 06.13 | 09.11 | 07.30 | 07.43 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.56 | 14.06 | 14.19 | 17.46 | 15.57 | 16.10 | 19.31 | 17.45 | 17.58 |
| 30 | Сш | 13 | 07.03 | 05.19 | 05.33 | 07.37 | 05.58 | 06.11 | 09.09 | 07.28 | 07.41 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.58 | 14.08 | 14.21 | 17.48 | 15.59 | 16.12 | 19.33 | 17.47 | 18.00 |
| 31 | Чш | 14 | 07.02 | 05.17 | 05.32 | 07.35 | 05.56 | 06.09 | 09.08 | 07.26 | 07.39 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.59 | 14.10 | 14.23 | 17.50 | 16.01 | 16.14 | 19.35 | 17.49 | 18.02 |

## Көч бәйгедә сынала

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Яр Чаллы мөхтәсибәте каршында эшләп килүче "Хәзинә" мөселман балалар клубында берсеннән-берсе мәгънәле кичәләр еш булып тора. Күптән түгел генә узган "Тамчы-шоу" интеллектуаль бәйгесе дә шундыйлардан, ул Мәүлид кичәсе уңаеннан оештырылган иде. Юк, һич кенә дә күпләргә таныш телевизион бәйге турында сүз бармый, нәкъ менә "Хәзинә"нең үзендә үткән матур бәйрәм хакында әйтүем. Бирегә шушы клубта гыйлем эстәүче кызлар белән Чаллының 29 нчы гимназиясе "Мирас" түгәрәге укучылары көч сынашты. Бишенче сыйныфта гына укуларына карамастан, бәйгедә катнашучы кызларның дини гыйлемнәренә сокланып туймаслык! Аларга пәйгамбәребез Мөхәммәт с.г.в. тормышына бәйләп тә, Коръәндәге сүрәләр буенча да, пәйгамбәрләр тарихы буенча да берсеннән-берсе катлаулы сораулар тәкъдим ителде, тик кызлар сынатырга ашыкмадылар. Җанатарларның көч өстәп утыруы гына түгел, үзләренең тәпле белемнәре дә таяныч булып торды.

Бәйге булгач, бәйге инде: аның җиңүчеләре дә, җиңелүчеләре дә була. Жюри составында Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, "Имам" мәдәни үзәге җитәкчесе Марсель Мөнәвиров, армрестлинг буенча спорт мастеры Энҗе Хәмидуллина булып, аларның гадел бәясеннән соң "Хәзинә" командасына — беренче, "Мирас" командасына икенче урын бирелде. Кызларның барысына да дипломнар, бүләкләр тапшырылды.




— Безнең кызларыбыз үстеләр, байтак кына белем тупладылар. Менә шул белемне башкаларга да күрсәтәсе, бүтәннәр белән бәйгедә сынап карыйсы килгән иде. "Тамчы-шоу" бәйгесе шул максаттан уздырылды, — ди "Хәзинә" клубы җитәкчесе Ләйсән Әхмәтшина.

Чыннан да, мондый ярышлар үз көчеңне бәяләп карау ягыннан да бик файдалы. Гыйлем — төпсез хәзинә, аның дәрәҗәсе бәйгеләр яссылыгында аеруча ачык күренә.

**Айгөл Әхмәтгалиева.**

**Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир
Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:
e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:
график буенча
8 декабрь 16 сәг.
фактта 8 декабрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**